# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Татар алфавитын тәртипкә китерү турында

Әлеге Закон татар алфавиты төзелешенең фәнни нигезләрен тагын да камилләштерү һәм тәртипкә китерү максатларында кабул ителә.

1 статья. Әлеге Законда татар алфавиты дигәндә билгеле бер тәртиптә урнашкан татар теле хәрефләре җыелмасы аңлашыла.

2 статья. Ә, Ө, Ү, Җ, Ң, Һ хәрефләренең татар алфавитында урнашуын түбәндәгечә билгеләргә:

Ә хәрефе А хәрефеннән соң, Ө хәрефе - О хәрефеннән, Ү хәрефе - У хәрефеннән, Җ хәрефе - Ж хәрефеннән, Ң хәрефе - Н хәрефеннән, Һ хәрефе Х хәрефеннән соң куела.

3 статья. Әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, татар алфавитын 38 хәрефле итеп, түбәндәге тәртиптә һәм әйтелештә расларга:

| Баш хәрефләр | Юл хәрефләр | Хәрефнең әйтелеше |
|---|---|---|
| А | а | а |
| Ә | ә | ә |
| Б | б | бэ |
| В | в | вэ |
| Г | г | гэ |
| Д | д | дэ |
| Е,Ё | е,е | е,йо |

| | | |
|---|---|---|
| Ж | ж | же |
| Җ | җ | җә |
| З | з | зе |
| И | и | и |
| Й | й | й кыска |
| К | к | ка |
| Л | л | эль |
| М | м | эм |
| Н | н | эн |
| Ң | ң | әң |
| О | о | о |
| Ө | ө | ө |
| П | п | пэ |
| Р | р | эр |
| С | с | эс |
| Т | т | тэ |
| У | у | у |
| Ү | ү | ү |
| Ф | ф | эф |
| Х | х | ха |
| Һ | һ | һе |
| Ц | ц | цэ |
| Ч | ч | чэ |
| Ш | ш | ша |
| Щ | щ | ща |
| Ъ | ъ | калынлык һәм аеру билгесе |
| Ы | ы | ы |
| Ь | ь | нечкәлек һәм аеру билгесе |
| Э | э | э |
| Ю | ю | ю |
| Я | я | я |

4 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына әлеге Законны үтәү буенча тиешле карарлар кабул итәргә.

5 статья. Татарстан АССР Югары Советы Президиумының 1939 елның 5 маендагы "Татар язуын латинлаштырылган алфавиттан рус графикасы нигезендәге алфавитка күчерү турында"гы Указын әлеге Закон гамәлгә кергән көннән үз көчен югалткан дип санарга.

6 статья. Әлеге Закон басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1997 елның 20 гыйнваре
N 997